ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

Большая Красная ур., 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 124

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«13» март 2019 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 30 октябрендәге 431 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсус коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан белешмәләр тапшыру тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 30 октябрендәге 431 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсус коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет иясе тарафыннан белешмәләр тапшыру тәртибенә, 3.1 пунктының алтынчы абзацын киләсе редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары беркетмәләре Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары беркетмәләрен рәсмиләштерү таләпләрен һәм күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары карарлары һәм беркетмәләре күчермәләрен Россия Федерациясе субъектларының дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вәкаләтле башкарма хакимият органнарына юллау кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 28 гыйнварындагы 44/пр номерлы боерыгы таләпләре нигезендә рәсмиләштерелергә тиеш.».

2. Хокук идарәсенең юридик бүлегенә (Н.Н.Воронская) дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче С.А. Крайнов